ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 26 апреле**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1162**

ТР, Зеленодольск шәһәре, Башкала урамындагы 27, 27а, 27б номерлы күпфатирлы йортлар өчен торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Торак кодексына (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән), РФ Хөкүмәтенең "Җирле үзидарә органы тарафыннан күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен идарәче оешманы сайлап алу буенча ачык конкурс үткәрү тәртибе турында" 2006 елның 6 февралендәге 75 номерлы карарына, РФ Хөкүмәтенең "Күпфатирлы йорт белән идарә итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге турында"2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карарына ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы, Зеленодольск шәһәре, Башкала урамындагы 27, 27а, 27б нче күпфатирлы йортлар өчен гражданнарның уңайлы һәм куркынычсыз яшәү шартларын тәэмин итә торган торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау, шулай ук күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә тоту өчен түләү күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

| № | Күпфатирлы йорт адресы | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.м. өчен түләү күләме, сум. |
|---|---|---|
| 1 | Башкала ур., 27 | 21,32 |
| 2 | Башкала ур., 27А | 21,24 |
| 3 | Башкала ур., 27Б | 21,25 |

2. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек белән элемтәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары бүлеге начальнигына әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының(http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында һәм «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарыруны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин